**МИНОБРНАУКИ РОССИИ**
**Нижнекамский химико-технологический институт (филиал)**
**федерального государственного бюджетного образовательного**
**учреждения высшего профессионального образования**
**«Казанский национальный исследовательский технологический**
**университет»**

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## МОРФОЛОГИЯ

МЕТОДИЧЕСКИЕ УКАЗАНИЯ

**Нижнекамск**
**2012**

**УДК 811.512.145**
**М 52**

Печатаются по решению редакционно-издательского совета Нижнекамского химико-технологического института (филиала) ФГБОУ ВПО «КНИТУ».

**Рецензенты:**
**Загидуллин М.М.,** кандидат педагогических наук, доцент;
**Саримова Р.Р.,** кандидат педагогических наук, доцент.

**Мирдиянова, Б.М.**
**М 52** Татарский язык. Морфология : методические указания / Б.М. Мирдиянова, Г.Г. Зарипова. – Нижнекамск : Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2012. – 42 с.

Составлены с учетом требований к преподаванию татарского языка в высших учебных заведениях. Способствуют развитию творческих способностей студентов, усвоению языковых знаний, привитию умений и навыков письменного выражения мыслей на татарском языке.

Предназначены для студентов всех форм обучения.

Подготовлены на кафедре иностранных языков (цикл русского и татарского языков).

**УДК 811.512.145**

© Мирдиянова Б.М., Зарипова Г.Г., 2012
© Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2012

## ЗАТЛАНЫШЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР

**1. Хикәя фигыль**

**<u>Биремнәр</u>**

1. Хикәя фигыльләрне анализларга, морфологик анализ ясарга.
2. Затланышлы фигыльләргә урнәктәгечә морфологик анализ ясау.

<u>Үрнәк:</u> күрмимен – хикәя фигыль, затланышлы, юклыкта, төп юнәлештә, хәзерге заманда, 1 зат берлек санда, җөмләдә хәбәр, тамыр сүз.

1. Дөньяның мин күрдем суын, күлен, урманнарын, тавын, чүлләрен. (Х.Туфан)
2. ...Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,
- Таш түгел лә, - бер киселгән баш килә. (Г.Тукай)
3. Көз җитте. Басуда игеннәр урылып, күптән ындырларга ташылып бетте. (М.Гафури)
4. Гөлшаһидә тиз генә урыныннан торды да ут кабызды, әлеге кайгылы авыр төсне күрмәс өчен, пәрдәне төшерде. (Г.Әпсәләмов)
5. Шул рәвешчә көннәр үткән, мин монда торганда чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен. (Г.Тукай)
6. Бакчада өздереп-өздереп кошлар сайрый, бал кортлары гөҗләшә. (Ф.Яруллин)
7. Кунакларыбыз, безнең каушап калуыбызны күреп, мөмкин кадәр тынычландырырга тырышалар. (Ф.Яруллин)
8. Яз җитеп, кояш нурлары көлеп карый башлау белән, тәрәзә төбендә яран, кына, роза гөлләре шау чәчәккә күмеләләр. (Р.Ишморатова)
9. Эшләгән эшләрнең күләме һәм әһәмияте ягыннан, мәгърифәт өлкәсендә, мөгаен, Ризаэтдин Фәхретдингә тиңнәр юктыр. (“Ризаэтдин Фәхретдин” китабыннан)
10. Дусларым шуа калдылар, мин, өйгә йөгереп, җилкәгә мылтык асу ягына карадым. (Г.Хәсәнов)
11. Кырык бишенче елның мул, калын карлы кышы апрель

урталарына кадәр нык кына торды. (М.Мәһдиев)
12. Бүгеннән ул яшь пионерларның Абдулла Алиш исемендәге сарае дип аталачак. (Г.Әпсәләмов)
13. Безнең илдә Муса һәм Алиш кебек геройларның исеме мәңге онытылмаячак. (А.Әхмәт)
14. – Менә безнең үзешчәннәр шундый булачак, - диде Курамшин. (Г.Ахунов)
15. Гөлгә карыйм, сиңа карыйм,
Син матур күренәсең. (Халык җыры)
16. Ядкәр язам мин сиңа, дустым,
Китәм ерак якларга. (И.Юзеев)
17. Ничә еллар гармун моңы булып,
Син яшисең, әти, күңелемдә... (Ш.Маннап)
18. Мин язам, шунда күрәм: лампа эчендә май кими. (Г.Тукай)
19. Коеп яңгыр яварга тотынды, шуның белән йөрәкләр тынычланды, тәннәр рәхәтләнде, йөзгә,күзгә яшәү өмете күтәрелде. (Г.Ибрагимов)
20. Дус көйдереп әйтер, дошман көлдереп әйтер. (Мәкаль)
21. Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, карышмый уйныймын, тик сине шартыма күнекмәссең дип уйлыймын. (М.Мәһдиев)
22. Башта күренгәнчә караңгы чырайлы кеше булып чыкмады. Серебряков бик җайлап, бик теләп сөйләште. (М.Мәһдиев)
23. Менә салкын кыш та үтә, яз якынлаша. Озакламый урман аланлыкларда чәчәкләр күренәчәк. (И.Гази)
24. Тәрәзәдән нур бөркелә, баш очында гына, өздереп-өздереп, бер кош сайрый. (А.Гыйләҗев)
25. Иңнәремдә тибри пар толымым,
Юл башында балкый ал таңым. (Ф.Гыйззәтуллина)
26. Зәп-зәңгәр төн.
Зәңгәр күл өстендә
Аккош кебек йөзә бер көймә. (Б.Рәхмәт)
27. Идел ага, Идел ага,
Тулып, ташып, мул булып,
Безне матур еракларга
Чакыра торган юл булып. (Ә.Исхак)

Бу таулар Урал тавының тармаклары булып, берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе биек булып күренәләр. (М.Гафури)

28. Әтәчләр моңайдылар,
Кешеләр уяндылар;
Тау артыннан таң атты,
Таң атты, кояш чыкты,
Бөтен авыл шаккатты. (Ш.Маннур)

29. Аккош күле. Төнге бакча.
Йокы алмый бөртек тә...
Кинәт чүгеп биһуш калдым-
Ис иңгән бит бөтнеккә. (З.Мансуров)

30. Бездә уен кайгысы калмады. Берәм-берәм өйләргә таралыштык. (М.Кәрим)

31. Еллар үтәр. Халык арасыннан яңадан-яңа талантлар чыгар, ихтимал, музыка даһилары да туар. (Ә.Еники)

32. Көндез йолдыз күрерлек, төнен җанвар ауларлык, эчендә ут янса да уфтанмас, өстенә тау ауса да сыкранмас ир егет кенә корыклый (арканлый) алыр, ди, ул атны. (М.Кәрим)

33. Керә белсәң халык йөрәгенә,
Ул сиңа да әйтер үз сүзен. (Ш.Маннур)

34. Юкка гармунчы түгелмен,
Ярсып бер уйнар идем,
Ярсып бер уйнар идем дә
Үксеп бер елар идем. (М.Кәрим)

35. Көн уртасына таба һава ачылды, кояш чыкты. (Ә.Еники)

36. Нигә болай бик әкрен кайтасыз, Талип абзый? (М.Хәбибуллин)

37. Иртәнге алты. Кояш инде кыздыра башлаган. (Г.Кашапов)

38. Кичке аваз чыңлый колагымда –
Өнди, дәшә, куалый, чакыра!
Көрәшергә һәм яшәргә куша
Туар таңнар, бәхет хакына. (Р.Низамиев)

40. Күпме таңны каршыладым,
Күпме йөзләр үтте каршымнан?!
Мин эзләдем сине еллар буе,

Син юк, ахры, безнең гасырда. (Р.Юныс)

41. Җир тетрәгән давыл уты, бәлки
Карлар белән эреп югалыр;
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр. (А.Алиш)

42. Унҗиденче елда, патшаны төшергән яз иде, Малмыҗ ягында бер байда көтү көттем. (М.Мәһдиев)

43. Халыкның рухи байлыгын мең еллар кичереп яңгырыткан җыр моңнарына мин гомерем буе мөкиббән, аның атаклы һәм гап-гади ул-кызларының бердәй якты күңелле булуларына сөенәм. (Ш.Галиев)

44. Төштән соң Валенсия аренасында үгез сугышы – коррида булачак. (М.Юныс)

45. Кыңгырау төсле чылтырап, тургайлар безнең теләкләрне кабатлар. (Ә.Баянов)

46. Мин амбарга кердем, чистартып салган ашлык өстеннән шуышып, иң ерак, аулак почмакка кереп яттым.

47. Шуннан инде хәлләр бераз үзгәрде.

48. Картлар, анда-санда гына күренгән, әле сугыштан алып кайткан ярасы төзәлеп тә җитмәгән ирләр, хатыннар, үсмерләр – көченнән килгән һәркем чалгы селти.

49. Алар туй ясап ике-өч ай үттеме икән, Хәбибулланы сугышка алып киттеләр. (Р.Фәизов)

50. Син бай булгач та, айга җиттем дип йөрисең икән. (Мәзәкләр)

51. – Нигә күңелсезләнәсең? – дип сорады. (Әкият)

52. Китап та укый алмыйм –
Хәлләремне бик аңлыйм ... (шигырьләр)

53. Ишетәсеңме, нинди шәп уйный. (Г.Бәширов)

54. Крестьян баласы, ир малай булса, җиде яшьтән атка, тырмага, сабанга йөри башлый. Сигездән-тугызга утауга, уракка кушалар. (Г.Ибраһимов)

55. Яфраклар коела, яфраклар...
Нәкъ шулай ел саен бу нәрсә...
Күбәләк шикелле талпынып

Очалар, аз гына җил бәрсә... (М.Әгъләмов)

56. Бу шатлыкка тагын бер куаныч өстәлде: күңелле сабан тургайлары да күренде. (Г.Хәсәнов)

57. Өйнең тәрәзәсе ачылмый, күрәсең, күтәрмәсе бозылган. (Г.Ибраһимов)

58. “Искәндәрнең яхшы яклары да күп, ул үзгәрер әле”, - дип уйлый идем. (Г.Кутуй)

59. Мин синдә идеалымның кайбер якларын булса да күрермен дип өметләндем. (И.Юзеев)

60. Җиңеп кайтырбыз, җиңүдә
Бөтен киләчәк. (Ф.Кәрим)

61. Һава тәмам аязды, бары кояш батышында гына вак-вак болыт кисәкләре күренәләр. (И.Гази)

62. Ул үзе менә монда утыра, ә күңеле әллә кайларда йөри. (Ә.Фәйзи)

63. Озакламыйча зур үзгәрешләр булыр, тиздән куанычлы хәбәрләр ишетелер! (Г.Бәширов)

64. Гөлсем тракторы янында машинистны калдырды да телефонга йөгерде. (Г.Бәширов)

65. Әнине дә әллә ни юксынмадым, күңелсезләнмәдем дә ул көнне. (В.Нуруллин)

66. Алдагысын күз күрер ... (Р.Мөхәммәдиев)

67. Яз әле бураннар артында,
Үзенең вакытын ул белер.
Яз табар үз юлын,
Кавышыр көн килер,
Алмагач чәчәккә төренер. (Р.Әхмәтҗан)

68. Их дускаем, айга кара,
Мин дә айга карармын;
Күз нурларың айга төшәр,
Шуннан эзләп табармын. (Халык җыры)

69. Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп
Өйрәткән энесенә. (Г.Зәйнәшева)

70. Булган, ди, бер бабай. Аның булган, ди өч улы. (Әкият)
71. Сабантуй бәйрәме ике атнадан булачак. (Г.Б.)
72. Борынсыз чыпчык боз тишә. (Табышмак)
73. Тама-тама таш яра. (Табышмак)
74. Аяксыз, кулсыз капка ача. (Табышмак)
75. Шагыйрь яныннан үземне бурычлы кеше кебек хис итеп киттем. (Ш.Галиев)
76. Тәрәзәдән нур бөркелә, баш очында гына бер кош сайрый. (А.Гыйләҗев)
77. Миңсылу да кешеләр белән бергә көлде һәм әзрәк кенә кул да чапкан булды. (Ш.Камал)
78. Су юлы корымаган, кипмәгән. (Ф.Әһлиуллина)
79. Нинди һөнәрләргә өйрәтәчәк ул мәктәп? (А.Расих)
80. Үз авылым, үз почмагым сыендырыр әле. (Г.Бәширов)
81. Минем хәтеремә бер егет кереп калган. (М.Мәһдиев)
82. Матур җәйләр дә үтеп, яңадан көз җитте.
83. Агачларга төсле күбәләкләр булып кызыллы-сарылы яфраклар куна.
84. Сандугачлар да, бар тереклек шикелле, җылы көн көткәннәр.
85. Кошлар җылы якка китәргә җыеналар.
86. Озак та үтмәс, урман кышкы йокыга талыр.
87. Крестьян кузгалышы күршедәге Самара, Пенза, Себер губерналарына җәелә. (Кави Нәҗми)
88. Бик матур бер айлы кичтә, бу авылның бер егете
Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.
Тиз барып җиткән егет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән “тук та тук”! (Габдулла Тукай)
89. Яз елмаер тиздән, урманнарда
Ак каеннар яфрак ярырлар.
Чәчәк атар шомырт, бакчаларда
Сандугачлар тавышы яңгырарлар. (Муса Җәлил)
90. Ир егет үзе өчен туар, иле өчен үләр. (Мәкаль)
91. Батыр ярасыз булмас. (Мәкаль)
92. Менә шул бабай, үләр алдыннан, үзенә чакырды да, миңа бер

уч тутырып орлыклар бирде. (Галимҗан Ибраһимов)
93. Сафа белән Саҗидә Йосыф карт өенә чаклы бергә кайттылар. (М.Галәү)
94. Аның иркен күкрәгеннән чыккан тавышы тирә-якка таралып, моңлы һәм яңгыраулы авазы тын даланы уятып, җанландырып җибәрде. (М.Гафури)
95. Бер-бер артлы узучы чана табаннары, пычак кайрагандагы төсле, тешкә тиюче тавыш чыгарып, өзлексез шыгырдыйлар. (К.Нәҗми)
96. Ул да түгел, баскычта Сәйфи үзе күренде. Этен ачуланып туктатты да кызулап урамга чыкты. (Г.Бәширов)
97. Ул фәкать аш вакыты җиткәч кенә кухнядан чыга.
98. Сибәләп кенә үтеп киткән төнге яңгырдан соң гаҗәеп аяз таң атты.
99. Люкс ышандырмыйм, әмма беренче класста аерым каюталар булачак.
100. Ишек шалтырап, шундук ябылды.
101. Поезд Түмән станциясенә килеп туктады.
102. Җил исте, агачлар чайкалып китте, җиргә сары яфраклар коелды.
103. Матур җәйләр дә үтеп, яңадан көз җитте.
104. Агачларга төсле күбәләкләр булып кызыллы-сарылы яфраклар куна.
105. Сандугачлар да, бар тереклек шикелле, җылы көн көткәннәр.
106. Кошлар җылы якка китәргә җыеналар.
107. Озак та үтмәс, урман кышкы йокыга талыр.
108. Нигә болай бик әкрен кайтасыз, Талип абзый? Мидхәт аны куып җитеп, янәшә атлап китте. (М. Хәбибуллин)
109. Ишетәсеңме, нинди шәп уйный? (Г.Бәширов)
110. Кызларның шул булыр инде аларның, алар һәрвакыт шулай һавалы булалар.
111. Рухны күтәрә, дәртне уята, тәнгә көч бирә салкынча таң.
112. Ни әйтәсез, авылдашлар, киңәшләрегезне бирегез.
113. Мин ап-ак кар диңгезенә кереп чумам.

114. Тирә-юньдә бернәрсә дә күренми.
115. Урман киекләре, тырышып-тырмашып, кышка азык әзерли.
116. Болыннарда төрле ислэрдән башлар әйләнә.
117. Яраттык, Без дә бик яраттык!
118. Юлың озын булыр,
Күп узарсың –
Атлау гына кирәк.
119. - Менә нәрсә, Лотфулла абзый. Иртәгә биредә савучылар, терлекчеләр белән җыелыш үткәрәбез. (М.Хәб.)
120. – Бүген үк күченеп кил. Син килеп җитмичә торып, мин беркая кузгалмаячакмын, олыг ана, - диде ул. (Н.Ф.)
121. Каюм Насыйри дәреслекләр язуга керешә. (С.Фәйзрахманова)
122. Тел турында дистәләгән мәкаль бар. (С.Фәйзрахманова)
123. Җәй узды да китте. (С.Фәйзрахманова)
124. Язгы ялларны бик кыска ясаганнар. (С.Фәйзрахманова)
125. Вакыйгалар бик зур тизлек белән алмашына. (С.Фәйзрахманова)

**2. Боерык фигыль**

**<u>Биремнәр:</u>**

1. Боерык фигыльләргә морфологик анализ ясарга.
2. Фигыльләрнең нигезен билгеләгез, төркемчәләрен әйтегез:
Карана, сөйләтми, укытса, эшләнәчәк, күренер, яздырмасак, кайтарачаклар, юындырыгыз, әйтерләр, яудыргансыз, көлешсеннәр, егылма, агызырбыз, очрашачаклар, тектерсеннәр, күзәтсәләр, сөйләшсәк, яздырыгыз.

1. Яшә минем республикам, Яшә Казан каласы! (Халык җыры)
2. Шауласын, гөрләсен, безнең җыр, еракка яңгырасын безнең җыр! (Ә.Ерикәй)
3. Әйт әле, Күбәләк, сөйләшик бергәләп... (Г.Тукай)
4. – Инструктор! Әйдә кайтыйк инде. (С.Баттал)
5. Әтиең еракта калган, онытылган шәүләсе миңа яный: - Ялганлама. Тик дөресен генә сөйлә! (М.Мәһдиев)
6. - Әйдәле, Акбай, өйрән син, арт аягың белән тор;

Аума, аума, туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр! (Г.Тукай)

7. И кояш! Тизрәк җылыт җирне, терелдер дөньяны. (З.Ярмәки)
8. Аеруча зур упкын тирәсендәге су өсте беркайчан да боз белән капланмый.(1991 ел календареннән)
9. Алтының белән мактанма, акылың белән мактан. (Мәкаль)
10. Чү! Тукта, җил... Яшьлек гомереңең газаплы да, ләззәтле дә башланган сукмагында утырган ветеранның аксыл чәчләренә кагылма, ул чәчләрне тарама. (М.Мәһдиев)
11. Мөмкин булса, укып карагызчы, Камил абый. (А.Расих)
12. Гафу итегез, нервылар какшаган. Аңлагыз хәлемне. (М.Галиев)
13. Хәзер үк Каенсарның тимерче икәнен Гаязга хәбәр итегез. (Р.Миңнуллин)
14. Тынма, эшлә, и сабый, бел, Тәңредән эшләргә көн... (Г.Тукай)
15. Кил әле, Иделнең җиләс җиле,
    Юлларга чәчәкләр сип әле. (Х.Туфан)
16. Оч, сайра, кошчык, канатлан
    Һәм бер дә китмә бездән:
    Без яшел бакча итәрбез
    Бөтен шәһәрне тиздән!
17. Буең зурмы дип сорама,
    Уең зурмы дип сора.
    Уйлый белгән кеше генә
    Кешене куандыра. (Ә.Ерикәй)
18. Рәхмәт сезгә, кадерле укытучым, мең-мең рәхмәт барысы өчен! Тагын да бик-бик озак яшәгез! (Ә.Фәйзи)
19. Ниятең дә, планың да бик әйбәт. Ләкин, берүк, әйткән сүзләрең шушында гына калсын. (М.Әмир)
20. Тыңла әле син мине... Киңәшемне тыңла, сүзләремне исеңдә тот. (Г.Кутуй)
21. Бар, улым, - диде бабай, - Маһруй апаңа әйт, башка ат җибәрсен. (Р.Батулла)
22. Тукта әле син, алай кызма әле, Сәкинә. (В.Нуруллин)
23. *Курыкма*, балам, хәзер ... хәзер бетә. *Йом* күзеңне, күзең

*күрмәсен*. (М.Җәлил)

24. Җәй сиңа эсселек биргән
    Һәм әйткән: сеңел, менә
    Беразын куеныңа сал,
    Калганын – йөрәгеңә. (Л.Зөлкәрнәй)
25. Боз катлавы эрегәч, җир өстенә умырзая чыга, карагыз! (Ә.Фәйзи)
26. Эш кенә - көч, эш кенә - ир ирлеге;
    Әй, гражданин! Әйдә, эшкә кил бире!
    Кыс тимерне! Ал чүкечне, балтаны!
    Бәр тимергә тукмагыңны! Бәр тагы! (Н.Исәнбәт)
27. Моннан гыйбрәт ал, угълым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә. (Дәрдемәнд)
28. –И-и, Миңлебай улым, алай димә син! (М.Мәһдиев)
29. Күрәм озак, олы урау булыр,
    Син көт, бәгърем, өзмә өметеңне. (М.Җәлил)
30. – Син бер дә курыкма, килен ... Син ят, ял ит әле.
31. Яле, әзерләгез акчаларыгызны!
32. Сөйләп җибәр әле безгә планнарыңны! (А.Гыймадиев)
33. – Тукта, - ди, - бераз сабыр итегез, - ди. (Әкият)
34. – Безнең Казан артлары кияү кыстый белмиләр, авызыңны ачып утырып ач калма, кыстаганны көтмә, килгән ашның берсен дә ашамыйча кире җибәрмә, үзең анда сөйләшмә, - дигәннәр. (Мәзәкләр)
35. – Безне шундый-шундый җиргә күчерегез, минем әмеремнән башка берегез дә кеше күзенә күренмәгез, - ди. (Әкият)
36. Барсын илгә минем йөрәгем. (М.Җәлил)
37. Тәкъдимем шул: күрше авыл белән берләшеп, бу бинины быел ук салып бетерик. (Г.Бәширов)
38. Мин шәһәрдән кайтканчы, син безнең өйдә торып торырсың әле. (Ф.Хөсни)
39. Җиңүгә һәрберебез лаек өлеш кертик! (Г.Кутуй)
40. Әй, күке! Нигә сагышланасың, миңа сереңне әйт әле! (Ф.Яруллин)
41. Менә бу кешегә бер динарлык бал сатып чык. (Туган тел

мәзәкләре)
42. Менә, апаң белән дә исәнләш. (Л.Сабирова)
43. Кисмәгез сез юкәләрне,
Чәчәк аткан чагында. (Җыр)
44. Там, беренче язгы тамчы, там, сөендер дөньяны.
И кояш! Тизрәк җылыт җирне, терелдер дөньяны! (З.Ярмәки)
45. Чү, алай итмә, олан. Сындырасың ич җанашымны, ычкындыр әле, ычкындыр. (Ә.Гаффар)
46. Нихәл, иркәм, мияубикәм,
Килче, кил миңа,
Нинди төшкәй күрдең, пескәй,
Сөйләп бир миңа. (Н.Исәнбәт)
47. Сез аны озак борчымагыз зинһар. (А.Расих)
48. Куегызсана, минем әдәбият герое булырлык нинди эшем бар. (Ф.Хөсни)
49. Ләкин, берүк, әйткән сүзләрең шушында гына калсын. (М.Әмир)
50. Мөмкин булса, укып карагызчы, Камил абый. (А.Расих)
51. Иртәгә сәгать 8-гә килегез. Дәрескә яхшылап әзерләнегез. (С.)
52. Китәргә рөхсәт итегез. (И.Н.)
53. Син шикәр сал сүзгә, мин – ачы дәва –
Сиздерик ачы-төчеләрне аңа. (Г.Монасыйпов)
54. – Тынычлан! – дим мин аңа. (М.Галиев)
55. – Кит аннан! Гайбәт сөйләшмә! (М.Галиев)
56. Аз сөйлә, күп эшлә.
57. Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.
58. Көндез таш ват, төнлә тыныч йокла.
59. Уйнавын уйна, эшең турында да уйла.
60. Хезмәт ит тә мактан, уйнап көл дә шатлан.
61. Шәһәр җырын җырлыйм, тыңлачы,
Улың белән кушылып җырлачы. (Һади Такташ)
62. Ал калфагың кисәнә, кыңгыр салып йөрсәнә. (Җыр)
63. – Барыгыз, туганнарым, качыгыз, җыегыз халыкны,

дөмектерегез шушы мәлгүнь Аксактимер этләрен – дип, ул энесен һәм абыйсын озатты. (риваятьләр һәм легендалар “Рабига күле”)
64. Алпамша әйтә:
- Син,- ди- минем чүен зиндан өстенә менеп, рәшәткәне алмаз белән сыз,- ди, - аннан соң мин үзем ачармын,- ди. (Әкияти дастан “Алпамша”)
65. – Ак Күбек, җанымны кыйнама, аягымда алмазым бар, син аны ал! Синең кылчыгың моңа үтмәс. (Дастан “Ак Күбек”)
66. – Паспортларыгызны күрсәтегез! – дип боерды офицер Таҗи белән Фәхригә. (“Ак Күбек”)
67. – Нык тор, приказсыз чигенмә. Мин озакламый килермен, - дидем Ткачка. (Г.Сафиуллин)
68. Чылбырдай тезелеп кайтыгыз, торналар! (И.Ганиева)
69. Уйныйк әле, дулкыннардай, кочагында Иделнең. (Р.Миңнуллин)
70. Әнә су өстендәге тәңкәләргә кара.
71. Карагыз, биредә нинди матурлык!
72. Юк, юк, беркая да җибәрмим.
73. Ап-ак кар түшәлгән перронга төшәргә өлгермәдек, тагын боерык:
- Тезләнегез! Кыбырсымагыз!
74. Кирәк-ярак алыгыз, - диде надзиратель, ишекне ачып.
75. Караңгы коридор буенча бераз атлагач, яңа әмер:
- Тукта!
76. Ул гына исән булсын! Ул гына исән-сау кайтсын! (Т.Гыйззәт)
77. Йорт эчендәге бернәрсәгә дә тимәгез. Һәр әйбер үз урынында торсын.
78. Башта киселгән агачның хакын түләсен, тагын шуның урынына биш төп агач утыртып үстерсен.
79. Йөр, күр, бел син күп җирләрне, күп илләрне.
80. И, сабыйлар эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә - эш.
81. Чыкчы, и фикрем кояшы!
82. Йөрәккә кунган шикелле, сайрамакчы, кит инде!

83. – Аша, хайван, аша, - дип, Шәяхмәт абзый атына ягымлы дәшеп алды.(М.Галиев)
84. – Бар, ат менеп базарга чап, малайдан сорашып кайт! – дигән. (Ә.Еники)
85. Сөйләмә, кирәкми, барысы да
Күңелдә, күңелдә, күңелдә. (С.Хәким)
86. Полицейский, кулына тотып йөргән наганын аңа төбәп: “Кузгаласы булма! Кулыңны күтәр!” – дип акырды.
87. Иртән торгач та юын һәм дәресеңне укырга тотын. Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн.
88. Үлем турында уйлама, Илең турында уйла. (Ф.Кәрим)
89. Кузгал, уян коллар, ачлар дөньясы... (И.Салахов)
90. Я, егет бул, йөрмә газапланып. (И.Юзеев)

### 3. Шарт фигыль

**<u>Биремнәр:</u>**

1. Төрле фигыль төркемчәләре ясап, юнәлешләргә куеп әйтегез:
Уйлау, бизәү, кайту, ябу, сөртү, бару, йоклау, эшләү, яшәү, көлү, язу, кию, юу, карау, утыру, сөйләү, елау, килү.
2. Бирелгән сүзләрдән фигыльләр ясап, күрсәтелгән формаларга куегыз.
Канат – йөкләтү килеше, билгесез киләчәк заман, 2 зат берлек сандагы хикәя фигыль;
Май – төшем юнәлеше, юклыкта, 3 зат берлек сандагы шарт фигыль;
Эш – уртаклык юнәлеше, билгеле киләчәк заман, 2 зат күплек сандагы хикәя фигыль;
Борау – йөкләтү юнәлеше, 3 зат күплек сандагы боерык фигыль;
Тавыш – уртаклык юнәлеше, юклыкта, хәзерге заман, 3 зат күплек сандагы хикәя фигыль;
Җыр – төшем юнәлеше, билгесез уткән заман, 3 зат күплек сандагы хикәя фигыль.

1. Кулың пакь булса, йөзең ак. (Мәкаль)
2. Әгәр дә ул бер сәгатьтән килеп җитмәсә, җыелыш булмый

калачак. (К.Нәҗми)

3. Сугыш заманасында нинди эш килеп чыкса, барысын да маташтырды. (И.Гази)

4. Үләннәр сусыллыгын җуйса да, чәчәкләр күзгә күренеп үк азая, картая, тоныклана торса да, әле юк дип тә әйтеп булмый аларны. (Г.Хәсәнов)

5. Яңгыр чыннан да ничек кинәт башланса, күңеле булгандай, шулай тиз тынды да. (Г.Хәсәнов)

6. Ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җиргә син ничек килеп җиттең? (Әкият)

7. Каты йөрәк бер яшәсә, изге йөрәк мең яшәр. (Мәкаль)

8. Теләгең саф булса, тормышыңда тап булмас. (Мәкаль)

9. Бәлки, мине искә алып,
Улым, дияр Туган илем. (Н.Дәүли)

10. Казанга якын барсаң, карасы йогар, яманга якын барсаң, бәласы йогар. (Мәкаль)

11. Яумасаң да күкрә, көчең җитмәсә дә, сер бирмә. (Мәкаль)

12. Сабакка калмаса соңга, борылмый барса, уң – сулга,
Уенга калмаса ихлас – менә бәхете аның шунда. (Г.Тукай)

13. Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен... (М.Җәлил)

14. Телен тешләп бер эшкә тотынса – аңа эш чыдамады. (М.Мәһдиев)

15. Чакыручы булган булса, мин дә барган булыр идем. (Ф.Хөсни)

16. Аерылсагыз, айга җитмәссез; бүленсәгез, бүген бетәрсез; бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез, - дигән Җирән кашка. (А.Алиш)

17. Йокыга китсәм, шул уйларымнан саташып уянам. (Р.Мөхәммәдиев)

18. Әгәр илдән хатлар килса –
Мин бәхетле.
Туган якны төштә курсәм –
Мин бәхетле. (М.Фәйзуллина)

19. Әгәр син миңа яхшылык эшләсәң, сугыш беткәч, мин сиңа

очып килермен һәм синдә кунак булырмын. (Г.Кутуй)
20. Аз гына белсәң, укытучыга ярдәмгә кил. Ул бит үз эшенең нәтиҗәсен белер өчен сыйныфтан җавап көтә. Син ярдәм итсәң, ул сине ташламый. (М.Мәһдиев)
21. Илең турында уйласаң, гомерең озын була. (Ф.Кәрим)
22. Сөн буена кайтсам, әллә нишлим –
Кайтам кебек мин үткәнемә. (Р.Миңнуллин)
23. Илне саклау өчен чакыру килсә,
Беләм: мин беренче барсам,
Син миннән дә элек барырсың. (Һ.Такташ)
24. Җиңелмә сүздә, җиңелсәң –
Җиреңне дә дауларлар.
Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар. (Р.Әхмәтҗанов)
25. Сандугачка каршыга биргән җавабында бала:
“Юк, сөекле сандугачым, уйнасам, дәресем кала.
Туктале, бетсен дәрес, әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!” (Г.Тукай)
26. Ни тырышсам да, кызны аермачык таный алмадым. (А.Гыйләҗев)
27. Урманга керсәң, сызгырып кер,
Селкенмәгән агач калмасын. (С.Хәким)
28. Әгәр ирекле, мөстәкыйль тормыш белән яшәүче булсам, һичшиксез, Тамчыгөлне туган йортына кайтару өчен кулдан килгәннең барын да эшләгән булыр идем, һичшиксез кайтачак иде ул!
29. – Монда хәтле кайтып, туган нигеземне күрми үтсәм, әтием белән әнием рәнҗер төсле ...
30. Хәлемнән килсә, бөтен дөньясын үзгәртер идем! (А.Гыймадиев)
31. Бер хәрефен алыштырсаң,
Була печән чабарга. (Шигырь)
32. – Һи, аны да белмәсәң! (Мәзәкләр)
33. – Ярый, - дигән ул, - ашасак, ашыйк. (Әкият)
34. Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,

Туган телең үги калмаса;
Җаның салып әйткән әткәң сүзен
Синең аша балаң аңласа. (Р.Фәйзуллин)
35. Иртәләр җитте исә,
Яктыра кырларда юл. (Һ.Такташ)
36. Иптәш буласың икән, рәхим ит, арага кер. Борыныңны күтәреп йөрисең икән, үзеңә үпкәлә. (Г.Коләхмәтов)
37. Бакчага сикереп төшеп качарга өлгермәгән булса, Хәлимнең аркасына шактый каты төшкән булыр иде. (И.Гази)
38. Арттагы солдатларның берсе фонарь кабызса да, төнге пычрак юл яктырмады. (К.Нәҗми)
39. Чакырсам да, кошчык, син бу йортка үзең теләп очып кермәссең. (М.Җәлил)
40. Илең турында уйласаң, гомерең озын була. (Ф.Кәрим)
41. Зиһенен нәрсәгә генә юнәлдерергә тырышса да, анасының кичәге сүзе аның колагыннан китми иде. (Г.Ибраһимов)
42. Син алып китсәң – анасыз тилмерәчәгемне, әни янында калсам - әтисез ятимә булачагымны башыгызга да китермәгәнсез. (Г.Мөхәммәтшин)
43. Әгәр дә, капитанның гөнаһ кылуы хак булып, юлдагы шоферны бензин сибеп яндыручылар чыннан да Горелов белән Хорошев булсалар, ул чагында бу эшкә гел яңа күзлектән карарга туры киләчәк. (Р.Мөһәммәтҗанов)
44. Малдан ярлы калсаң кал, акылдан ярлы калма. (Мәкаль)
45. Каты йөрәк бер яшәсә, изге йөрәк мең яшәр. (Мәкаль)
46. Гомергә ул тукымалар
Сугып көн итә,
Бер хәрефен алдың исә -
Мәктәпкә китә. (Табышмак: укучы)
47. Ояга кеше кулы тисә, кызылтүшләр кошчыкларын калдырып ташлап китәләр. (Г.Хәсәнов)
48. Ул берәр кешегә яхшылык эшләмәсә, көнен бушка узган дип исәпли. (Р.Ишморат)
49. Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, коенып ята идек.

(Г.Тукай)
50. Яумасаң да күкрә, көчең җитмәсә дә, сер бирмә. (М.)
51. Ул әйтсә дә, мин ишетмәдем. (С.)
52. Әгәр мине сорасалар, кайда киткәнемне әйтерсез. (К.М)
53. Син туктасаң – туктый,
Син барсаң – бара.
Ул нәрсә, я уйлап кара. (Табышмак)
54. Ул булса – көн була,
Ул булмаса – төн була. (Табышмак)
55. Төнлә баксаң – күк тулган,
Иртән баксаң – юк булган. (Табышмак)
56. Җәй җитсә, без авылга кайтабыз. (М.Юныс)
57. Бу китапны укысаң, күп яңа мәгълүмат алырга мөмкин. (М.Галиев)
58. Их, белсәң иде эчемдә нинди утлар дөрләгәнен.
59. Әгәр сезнең шундый дустыгыз булса, аны саклагыз.
60. Язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма, көзге боз көзге калынлыгы булса да ышан.
61. Кая барсам, кайда йөрсәм дә, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем. (Габдулла Тукай)
62. Җәй эшләсәң, кыш ашарсың. (Мәкаль)
63. Озак йөрсәк тә, бүтән ул көнне бер гөмбә дә таба алмадык. (Туган Як газ.)
64. Үзе каммун булмаса да, барыбер алар белән бер табактан ашый, алар җырын җырлап йөри!..(Галимҗан Ибраһимов)
65. – Шуннан соң да ризалык бирмәсә, үзенә үпкәләр... (М.Гәләү)
66. – Картлар рөхсәт итсә, күңелемдәге бер уйны әйтер идем, - диде ул, тынлыкны бозып. (М.Гәләү)
67. Кырга чыксам, җылы җилләр чәчтән сыйпап иркәли. (Р.Әхмәтҗанов)
68. Җил юк, җил чыкса, Данис күтәрер иде дә очар иде дулкыннар өстеннән. (М.Хәбибуллин)
69. Очны очка ничек кенә ялгарга тырышсалар да, сигезенче классны тәмамлый алмадылар алар. (К.Тинчурин)

70. Күңелендә сөю чаткысы булса, хат язар яки Акъярга килеп китәр иде.
71. Ул үзе бала көтә, шунлыктан кулына нәни бала алса, күңелләре әллә нишләп китә иде.
72. Пристаньда күпме кеше булса, барысы да кычкырдылар.
73. Әмма, туюын туйсак та, күңел туймый.
74. Әгәр дә уйдырма гаепләү актыгызда күрсәтелгәнчә, Совет хөкүмәтен җимерергә уйлаган булсам, - тагын кабатлыйм, андый ният миндә булган юк, - кемнәргә, нинди көчләргә таянган булыр идем?
75. Тотып калмасаң, чана үзеңне дә өстерәп алып төшеп китәчәк.
76. Их, белсәң иде эчемдә нинди утлар дөрләгәнен.
77. Әгәр сезнең шундый дустыгыз булса, аны саклагыз.
78. Әгәр Рифкать гранатаны кулдан ычкындырса, әтисе дә, әнисе дә, Әнфисә дә, Азат та, дуслары да – барысы да шартлаячак, юкка чыгачак. (Р.Вәлиев)
79. Җырлырым...
...Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен. (М.Җәлил)
80. Сөн буена кайтсам, әллә нишлим –
Кайтам кебек мин үткәнемә.
Чишмәләрнең утлы суын эчсәм,
Куәт иңә бөтен тәнемә. (Р.Миңнуллин)
81. Үзе өйдә булса, килеп тә йөрмәс идем.
82. Әгәр дә сезгә дарулар ярдәм итмәсә, үләннәр кайнатып эчеп карагыз әле.
83. Эшләмәсәң җәй көне, ни ашарсың кыш көне.
84. Эх, минем дә шундый абыем булса!
85. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы.
86. Туган җирем! Җәең үтсә,
Сокланырлык көзең бар... (Р.Гәрәй)
87. Ояла-ояла гына булса да, укырга ниятем барлыгын аңлаттым. (М.Әмир)
88. Ике кулың ни эшләсә, ике иңең шуны күтәрер. (Мәкаль)

89. Үзеннән олырак кешеләр авызыннан ни чыкса, аның шуңа ышанып яши торган чагы иде. (Ә.Еники)
90. Иртәләр җитте исә,
Яктыра кырларда юл. (Һ.Такташ)
91. Шунда үзең минем янга килгән булсаңчы!
92. Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,
Туган телең үги калмаса;
Җаның салып әйткән сүзең
Синең аша балаң аңласа. (Р.Фәйзуллин)
93. Эшләп үлмәссең, чирләп үләрсең. (Мәкаль)
94. Ашыккан ашка пешәр. (Мәкаль)
95. Куркак тереләй үләр. (Мәкаль)

## ЗАТЛАНЫШСЫЗ ФИГЫЛЬЛӘР

### 4. Сыйфат фигель

**Биремнәр:**

1. Сыйфат фигыльләргә анализ ясарга.
Үрнәк: укый торган (малайлар) – сыйфат фигыль, затланышсыз, барлыкта, төп юнәлештә, хәзерге заманда, җөмләдә аергыч булып килгән, ясалма суз.
2. Киләчәк заман сыйфат фигыль формаларына мисаллар китерергә.

1. Без карый торган фильмның режиссеры – С.Школьников.
2. Алар яши торган йортка газ кертелгән.
3. Сүзен уйлап сөйләмәүчеләрне мин гомумән яратмыйм. (Г.Әпсәләмов)
4. Мин китәсе поезд курше станциядән чыккан. (Г.Минский)
5. Ул балалар күңелен яхшы белүче, аларның зәвыкларын тиз тотып алучы, алар турында һәрвакыт кайгыртып торуны үзенә бәхет санаучы, кече күңелле, олы җанлы кеше иде. (Ә.Камал)
6. Һәр якның әнә шул бөек хис белән бергә үрелеп мактаулы эшләре, данлы кешеләре бар. (Г.Бәшәров)
7. Карлыгачлар һавада очучы чебен-черки, башка бөҗәкләрне тотарга җайлашканнар. (“Хезмәткә - хөрмәт” китабыннан)
8. Профессор, урыныннан торып, ишектән килеп кергән кызга

каршы атлады. (Г.Әпсәләмов)
9. Хәсән ага Туфанның үземдә калган, әле дөнья күрмәгән хатларын, шигырьләрен кабат-кабат укып утырам. (Г.Минский)
10. Башланган эш – беткән эш. (Мәкаль)
11. Урманда яшәүче индеецларның тормышын сез белеп җиткермәгән кебек, аларда зур шәһәрләрдә кешеләрнең ничек яшәүләрен бик аз беләләр. (Н.Дәүли)
12. Апрель ае. Кояшлы бер иртә
Тотынуым булды каләмгә,
Килде хәбәр: син язачак кеше
Яңа гына очты галәмгә. (С.Хәким)
13. Әхәт үзе эшли торган нефть мәйданының матур табигатен, анда үзе белән бергә эшләүче иптәшләренең хезмәтен һәм йөзләрен оста чагылдыра ала торган рәссам иде. (А.Юсупова)
14. Кайгылы һәм авыр елларда ул
Изелгәнне яклап җырлады. (М.Җәлил)
15. Халкыбыз киләчәк тормышы яхшыруына, бәйсезлек һәм тигез хокуклык өчен көрәштә җиңәчәгенә ышана.
16. Зур бу дөнья, гаҗәп киң бу дөнья,
Давыл җиңәр көче бар аның.
Сукмакларда һич өзелмәс кеше,
Үлән басмас ишегалларын. (С.Хәким)
17. Тапканнар өйрәнер нәрсә. Булгач-булгач шундый җыр булсын, аны ишеткән кеше таң калсын. (Н.Гыйматдинова)
18. Кызыл икән, ал икән,
Яшел икән, сары икән,
Кеше йөрмәс, атлы үтмәс
Шундый күпер бар икән. (Табышмак)
19. Алдыбызда ята кара икмәк,
Телем-телем итеп киселгән,
Өй эчләре шундый аңкып тора –
Яңа пешкән икмәк исеннән. (Р.Гәрәй)
20. Тик үзебез туып-үскән җиргә
Тиңдәш булыр җирне тапмадык. (С.Урайский)
21. Аткан ук кире кайтмас,

Әйткән сүз эчтә ятмас. (Мәкаль)
22. “Сызгыра торган уклар”. (Н.Фәттах)
23. Хыялында үзен халык азатлыгы өчен көрәшүче егет итеп күз алдына китерә. (Г.Ибраһимов)
24. Кая гына карама, җан, күңел күтәрелә торган моңнар, матур күренешләр генә очрый. (Г.Ибраһимов)
25. Төн үтә, таулар артына
Тулган ай бата,
Украина кырларында
Язгы таң ата. (Ф.Кәрим)
26. Күптән күрешмәгән дусларда сөйләшер сүзләр күп табылды. (Ф.Ә.)
27. Халыкның рухи байлыгын мең еллар кичереп яңгыраткан җыр моңнарына мин гомерем буе мөкиббән, аның атаклы һәм гап-гади ул – кызларның бердәй якты күңелле булуларына сөенәм. (Ш.Галиев)
28. Аннан соң бу йортта яшәүче кешеләрнең күпчелеге авылдан килеп белем алган, зур укыган кешеләр. (М.Мәһдиев)
29. Әммә әле бит, безнең заманда, революция алдыннан яисә революциядән соң чыккан көйләр дә байтак кына... (Г.Бәширов)
30. Киләсе атна истәлекле, чөнки егерменче декабрь Корбан бәйрәме.
31. Минем аңа әйтәсе сүзем бар иде.
32. Укучы бала чиста, пөхтә, игътибарлы һәм ихтирамлы булырга тиеш.
33. Трактор заводында эшләүче инженер, авылга кунакка кайткач, бер бабайның чабата ясап утыруын күргән. (Мәзәкләр)
34. Хәйретдиннең күрше авылда умартачы дусты бар икән. (Мәзәкләр)
35. Шул вакыт диңгез патшасының кызы да: “Минем йомышларымны үтәүче егет шушы түгелме икән?” – дип, Гүзәлхан егетен күрсәтте. (Әкият)
36. Кызып бии торган яшь сугышчы кинәт туктады. (Г.Гобәй)
37. Камил аңа бу сирәк очрый торган хәлнең ничек булуын тәмамлап сөйләп бирер. (М.Әмир)

38. Аяз, дулкынланып, болынга төшүче олы юлга күз салды. (Г.Бәширов)
39. Аткан ук кире кайтмас,
Әйткән сүз эчтә ятмас. (Мәкаль)
40. Аюдан курыккан урманга бармас. (Мәкаль)
41. Шулай сөйләп бирдем дә, сөйләгәннәремә йомгак ясадым. (Г.Галиев)
42. Биктаһир үзен бер дә вакытка бирешер кеше кебек сизми иде. (Н.Әхмәдиев)
43. Кайтыр юл әйбәт кенә булыр кебек иде башта ... (Ф.Шәфигуллин)
44. Миннән соң туачак җырчыларның
Даны күмәр минем атымны ... (М.Җәлил)
45. Җырчы сандугачлар таң алдыннан бик каты сайрап арыганнар, хәзер яфраклар өстендә ялтырап ятучы чык тамчылары белән кипкән тамакларын чылатып йөриләр. (Ф.Яруллин)
46. Хәрәкәтсез калып тыңлап торган партизаннар кузгалышып куйдылар, тик берсе дә тынлыкны бозмады (Г.Гобәй)
47. Кичтән башланган яңгыр туктамады, каты җил исте, дөньяны яктыртып, яшен яшеннәде, тау-таш җимерелгәндәй гөрелдәп, күк күкрәп үтте. (Г.Ибраһимов)
48. Җемелдәгән йолдызлар, каядыр ашкынган кометалар арасында җир шары үзенең мәңгелек юлын дәвам итә. (М.Маликова)
49. Хөкүмәт тарафыннан башкарылган репрессияләрнең йомшаруы нәтиҗәсендә төрки-татарлар арасында баш күтәрүләр булмый. (Г.Исхакый)
50. Әйтелмәгән мәхәббәтем,
Әйтелмәгән мәхәббәтем,
Яндыра йөрәгемне. (Җыр)
51. Сагышланган чакларыңны
Салма гел хатларга син. (Җыр)
52. Барыннан да элек, минем үзем торган йортны кире кайтып күрәсем килде. Ни булды икән анда? (Ә.Еники)

53. Бөере авырткannarга алма суының файдасы зур. Ул бөердән ташларны, комнарны, бүтән кирәкмәгән матдәләрне куа. (Календардан алынган)
54. Уфага бара торган пароходка утыртмыйлар әле. (Г.Әбсәләмов)
55. Ниһаять, менә ул мин эзләгән йорт. (И.Салахов)
56. Әйтер сүзләр эчтә калды бит. (Н.Фәттах)
57. Сөйләүче кешеләр бармы? (Х.Ә.)
58. Ял итүче кешеләр су буена киттеләр. (Г.С.)
59. Эскәмиядә утырган әбиләр елмайдылар. (Ә.Ф.)
60. Ләкин эшләп утырган кабинетның бусагасын атлап керүе булды, әзерләп куйган сүзләре башыннан чыкты да бетте. (В.Тельпугов)
61. Канаты бар – җилпеми,
Эче җылы – җил тими,
Корыч йөрәкле кош ул,
Безнең яраткан дус ул. (Табышмак)
62. Сөембикә бөтенләй көтмәгән-уйламаган яңалык әйтте. (Ф.Садриев)
63. Аннары тагаракта җылынган су белән икесе дә юындылар. (Ф.Садриев)
64. Ул арада юл идарәсенең чуерташ ташучы машинасы килеп туктады. (Ф.Садриев)
65. Җәйге эссе көннәрнең берсендә без дачада яшәүче апалар белән сөйләштек тә, балаларны урманга алып барып кайтырга булдык.
66. Төн буе койган яңгыр әле һаман туктамаган.
67. Эш эшләгән интекмәс, эшләмәгән көн итмәс.
68. Әйтер сүзләр эчтә калды бит.
69. Без күчәсе яңа йортның алдына гөлчәчәкләр утырттылар.
70. Ул кызга белдерәсе шатлыгының иң олысын юри соңга калдырган иде.
71. Мәктәптә укулар башланыр көн җитә. (Фатих Хөсни)
72. Казның ике канатын агай ике кызга биргән: “Сез бу йорттан очасы кешеләр”. (Әкият)

73. Авырмаган кеше ыңгырашмас. (Мәкаль)
74. Атмаган куян, асмаган казан. (Әйтем)
75. Алпамшаның элек куеп калдырган мылтыгы бар икән. (Әкияти дастан “Алпамша”)
76. Кичен күзен йомып, иртән керфекләрен ача торган тере чәчәгем. (И.Юзеев)
77. Ерак бабасы, атка атланып, бөтен Францияне тетрәткән рус гаскәрләренең алгы сафында, Парижга барып кергән.(Р.Харис)
78. Онытма син. Гел бергә идек. Аерылмас ике дус. (И.Юзеев)
79. Мансур җилкәнле көймәдә узып баручы таныш егетенә кул болгарга тотынды.
80. Без кайта торган бакча урман янында урнашкан.
81. Еракка-еракка җәелгән Идел дә тибрәнми.
82. Мин Ялтага килеп төшкән көнне үк Галимҗан Ибраһимов торган йортны эзләп киттем.
83. Аның өстендә аксыл-сары иркен күлмәк һәм шул ук материалдан тегелгән чалбар.
84. Җәйге эссе көннәрнең берсендә, без дачада яшәүче апалар белән сөйләштек тә, балаларны урманга алып барып кайтырга булдык.
85. Ниһаять, менә ул мин эзләгән йорт. Төн буе койган яңгыр әле һаман туктамаган.
86. Шигырь яратучы кеше берчакта да начар була алмый, чөнки шигърият күңелләрне яктыртып җибәрә, тормышыбызга ямь өсти. (Р.Миңнуллин)
87. Әйтерсең ул җиргә басмый, бәлки күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара. (Г.Ибраһимов)
88. Без барасы юллар якты.
Безнең юллар үр менә. (Г.Латыйп)
89. Олимпиадада җиңүче укучыларның барысына да бүләкләр бирделәр.
90. Этләрне өйрәтүче кеше аларны бик яратырга һәм аңларга тиеш.
91. Малайлар, шәһәрдән кайтучыларны каршы алырга дип, авыл башына җыелганнар иде.

92. Мондый эшкә гамьсез караучы кешеләр табыла икән.
93. Уенчыклар сатыла торган җирдә озын чират.
94. Аны намуслы, бары тик авырулар өчен генә яшәүче врач дип саный иде.
95. Башланган эш – беткән эш.
96. Син әйткән сүзләрне мин хәтерлим.
97. Ул килгәндә, поезд киткән иде инде.
98. Без барасы юллар озын әле.
99. Башкарасы эш күп иде әле.
100. Аннары тагаракта җылынган су белән икесе дә юындылар. (Ф.Садриев)
101. Бер сүз бар: үзе егылган еламас. (Мәкаль)
102. Тәрәзә төбе тулы кәгазьләр, папкаларга төрелгән кулъязмалар, уртада сулы графин, кырлы стакан, трубкасы зәңгәр изолента белән уралган телефон, карандашлар салынган пластмасс стакан, кергән кешегә утыру өчен, күне шактый кыршылган диван. (Ф.Са+дриев)
103. Белгән белгәнен эшләр, белмәгән беләген тешләр.
Кайда гына аяк басмадык;
Тик үзебез туып үскән җиргә
Тиңдәш булыр җирне тапмадык. (С.Урайский)
104. Вәли шул таушалган акчаны кесәсенә тыкты. (А.Галиев)
105. Аның ямалган бүреге кояшта ялтырап тора иде. (А.Галиев)
106. Тирән казылган чокыр тирәсендә йөрү куркыныч. (А.Галиев)

**5. Хәл фигыль**

**<u>Биремнәр:</u>**

1. Хәл фигыльләргә тулы морфологик анализ ясарга.

Үрнәк: чыккач – хәл фигыль, затланышсыз, барлыкта, төп юнәлештә, 3 нче төр, җөмләдә аерымланган хәл составында, тамыр сүз.

2. Хәл фигыльнең төрләренә мисаллар китерергә.

1. Колхозчылар килеп кергәч кенә исемә төште ялгыз түгелем. (Һ.Такташ)

2. Шуннан соң өч-дүрт көн үткәч, Сөләйман абзыйны Гаязов парткомга чакырды. (Г.Әпсәләмов)
3. Агачлар булмагач, бу урында кар да тизрәк эрегән һәм кар китәр-китмәс беренче яз чәчәге – умырзая да баш күтәргән. (Г.Ибраһимов)
4. Самавырын, балыгын табынга куйгач, әни алъяпкыч итәгенә төреп алып килгән бер яртысын да өстәлгә китереп утыртты. (Ф.Яруллин)
5. Базарбашы авыз эченнән генә ниндидер дога укыгач, куеныннан ачкыч чыгарып, бакыр сандыкның йозагын борып җибәрде. (Ф.Латыйфи)
6. Син куанганда куанып, син кайгырганда кайгырып, синең белән бергә сулап, бергә көлеп яшәүче кем? Әниең! (И.Гази)
7. Таң җилләре чәчләремне
Назлап сүтәләр. (И.Юзеев)
8. Яңгыратып тирә-якны,
Өзелеп сайрый сандугач. (Ә.Исхак)
9. Ай-һай ямьсез, ай-һай шыксыз булып калган тирә-як! (М.Хәсәнов)
10. Эшлим янып, җиң сызганып,
Илемне яратканга. (Җыр)
11. Язам менә тагын кыш турында.
Тынгы бирми карлар һаман да.
Бөтерелә-бөтерелә әнә
Бөдрә карлар ява Кабанга. (Р.Миңнуллин)
12. Муса Җәлилнең һәлак булуы турында хәбәр килгәч, шагыйрьнең язмышын ачыклау эшенә А.Фадеев турыдан-туры катнаша. (Р.Миңнуллин)
13. Илгә кайткач, урының түрдә булыр,
Яшь балалар алыр уратып. (М.Җәлил)
14. Аны чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар. (Ә.Еники)
15. Кар, күбәләкләр кебек оча-оча, бөтерелә-бөтерелә, тын гына яуды. (Р.Юсупов)
16. Ашка суган турыйм мин,

Көлә-көлә елыйм мин. (М.Фәйзуллина)

17. Куаналар өч-дүрт бүре моны күргәч,
Алларына сарык белән кәҗә килгәч. (Г.Тукай)

18. Малайлар, әйдәгез безнең коега кар тутырабыз. Ну, шапылдап төшә дә кое төбенә. (Н.Кәримова)

19. Кап-кара канатлы, кара карлыган кебек кап-кара балаларына карый-карый шатланганнар кара каргалар. (А.Алиш)

20. Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы агачларга посып. (Г.Тукай)

21. Миңа озын гомер тели-тели,
Кем булды, дип, улым – алтыным,
Өйдән-өйгә йөреп укыр идең
Окоплардан язган хатымны... (Ф.Кәрим)

22. Анда бик иртә, маякларны сүндергәнче үк, менәргә кирәк, диде этисе... Алар җитәкләшеп чыктылар. (Г.Гобәй)

23. Әбүгалисинә үзенең туганын олылап каршы алды. (К.Насыйри)

24. Алар көлгәч, Илсөяр өчен сер тагын да тирәнәя төште. (Г.Гобәй)

25. Җырлый-җырлый күтәреләм
Тормышым үрләренә.
Шатлыгым да, хәсрәтем дә
Тик туган җирдә генә. (Х.Халиков)

26. Әкрен генә таң килә,
Ак челтәрен үреп,
Җилкәннәрен киереп,
Илгә яңа ямь биреп. (Ә.Ерикәй)

26. Авыл артына, чирәмлеккә күтәрелеп, шуннан ашыкмыйча гына кайтырга булдылар. (Ә.Еники)

27. Кара диңгезгә җиткәч, радиограмма алдык: Жданов портында йөк төяп, Испаниянең Юарселона һәм Валенсия портларына юл тотарга тиешбез. (М.Юныс)

28. Бизәнү әйбере булганчы, алкалар изге талисман буларак кулланылганнар. (Календарь)

29. Бер көнне эти, ахшам намазыннан кайтышлый, авылының

мөзинен – Гайнетдин абзыйны, чәйгә алып керде. (Г.Бәширов)
30. Шунда, шатлана-шатлана, бәбкәләре белән казлар, үрдәкләр һәм нәни балалар коена. (Г.Кутуй)
31. Әледән әле табанга саргайган көзге яфраклар ияреп чыга.
32. Коңгырт чәчләрен, гадәттәгечә, җилкәсенә таратып салган.
33. Ишегалдының бер почмагында иске төпсез чиләк аунап ята.
34. Тамчыгөл, яшьле күзләрен бармак очлары белән генә сөртеп алды. (А.Гыймадиев)
35. Бер далада кәрван ял итәргә туктагач, дөяләр коры камыл чүпләп ашый башлаганнар. (Мәзәкләр)
36. Шулвакытта бөтен кешеләрне чыгарып, боларның икесен генә бикләп калдыралар. (Әкият)
37. Мин дә аны су астында ныклап таный алмадым. (Мәзәкләр)
38. Хөсәен бөгелә-сыгыла Sанияне биергә чакыра. (А.Гыйләҗев)
39. Күгәрченнәрнең өзелеп-өзелеп сайраулары ишетелә. (Г.Бәширов)
40. Анда бик иртә, маякларны сүндергәнче үк, менәргә кирәк, диде этисе ... Алар җитәкләшеп чыктылар. (Г.Гобәй)
41. Иртәнчәк көн ифрат суык иде, төштән соң аз гына йомшартып җибәрде. (Ш.Камал)
42. Сәфәргали туктаган төркем янына унтер-офицер чинындагы берәү килеп чыкты.(Ф.Хөсни)
43. Күңеле ямь тапмаганлыктан, ул монда үзенең иске генә булса да өен ташлап килде. (М.Гафури)
44. Тау итәгеннән, көмеш тасма сузылган төсле, кечкенәрәк елга агып ята. (“Казан утлары”)
45. Бергә булу минутларын
Өзелеп-өзелеп көтәмен. (Җыр)
46. Бөдрә таллар таң җилләреннән
Тирбәлә талгын гына;
Бер сандугач, өзелеп-өзелеп,
Моңнарын агылдыра. (М.Ногман)
47. Сагынышып кошлар кайта
Түгәрәк күлләренә.
Ояларын ясый алар

Тик туган җирдә генә.
Сандугачлар кунып сайрый
Талларның иңнәренә.
Дөнья ямьле, сулар тәмле
Тик туган җирдә генә.
Җырлый-җырлый күтәреләм
Тормышның үрләренә.
Шатлыгым да, хәсрәтем дә
Тик туган җирдә генә. (Х.Халиков)

48. Машина, борылып, икенче урамга китте. (З.М.)
49. Әти, кайтып, безне шатландырды. (Н.Д.)
50. Без, шатланып, әниебезне кочаклап алдык. (Ф.С.)
51. Шулай диде дә, Антоний кисәк кенә сәкегә сузылып ятты һәм ике кулын баш астына куеп, түшәмгә текәлде. (М.Хәбибуллин)
52. Хәлим хатны укып, гаҗәпкә калып, кызны кайтарып, Габдерәхим мөгаллим кызын соратып, әүвәл кызына хат язып сорар. (Г.Исхакый)
53. Приск аңа каерылып карап калды. (М.Хәбибуллин)
54. Анда сирәк-сирәк кенә ак болытлар, якты күкне чуарлап, сирпелеп торалар. (Ә.Фәйзи)
55. Наил атыла-бәрелә өстәл янына йөгерде. (Н.Гыйматдинова)
56. Туйганчы яуды яңгыр. (Г.Хәсәнов)
57. Ятып калганчы атып кал. (Мәкаль)
58. Кайтышлый, без әбиләргә кердек. (Г.Гобәй)
59. Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.
60. Беркөнне Раиләнең әтисе дә чана алып кайтты.
61. Үз чанасы булгач, тагын да күңеллерәк икән аңа.
62. Поезд киткәнче өлгерергә кирәк.
63. Тыштагы эшләрне караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. (Габдулла Тукай)
64. Яр буена шаулап килә дә җил
Башын сыйпый йомшак талларның,
Иркәләнеп таллар тирбәләләр,
Шәүлә төшә суга алланып. (Фатих Кәрим)

65. Закир, куплетны бетергәч, артистлар төсле елмаеп, залга баш иде. (Шәриф Камал)
66. Шәһәр читенә кайтып җитә дә, кием-салымнарын салып, Акбүз атны үләнгә җибәрә. (Әкияти дастан “Алпамша”)
67. Куркак кош, үзенең тоткынлыкка эләгәчәген сизенеп, бар көче берлә һавага күтәрелә башлады. (Дастан “Җик Мәргән”)
68. Чура батыр моны күреп, үпкәләп, кире бер җиргә ташланды. (Чура батыр хикәяте)
69. Күкнең болай баруын күреп, эт белән мәче дә бик борчылганнар. (мифологик хикәят “Күкнең күтәрелүе”)
70. Ул әйбәтләп әйтеп-әйтеп карады, билгеле. (Р.Низамиев)
71. Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк. (Г.Тукай)
72. Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли өмәләрдә күңел ачабыз. (Т.Гыйззәт)
73. Бары тик кыз күзләрен ачкач кына, аны, килеп җиткән врачлар кулына тапшырып, үзләре шыпырт кына китеп бардылар.
74. Бар да көтелмәгәнчә килеп чыкты.
75. Егет күзләрен чекрәйтеп, арты белән чигенә-чигенә китеп барды.
76. Институтның тулай торагыннан чыкканда, таң атып, кояш инде күтәрелә дә башлаган иде.
77. Әле генә парк өстендә куерып, тулганып, менә-менә салкын тамчылар белән коендырам дип куркыткан көзге шыксыз кара болытлар кинәт таралды.
78. Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.
79. Кичә сәхнәгә чыкканчы ук аның күңеле нәрсәдер сизенде, нәрсәгәдер җилкенде. (М.Мәһдиев)
80. Шаян тиен дә, чикләвекләр ашап, ботактан ботакка сикереп уйнамаган. (А.Алиш)
81. Кайтмый бүре – эзе дә юк, исе дә юк
Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә. (Г.Тукай)
82. Энем, егылып, аягын авырттырды.
83. Китапханәче сезгә кирәкле китапларны таба алмаган,

үзегезгә килеп эзләргә кушты.
84. Ул китаплар балалар өчен түгел бит, син аларны аңлап укыйсыңмы?
85. Кызлар, үзара сөйләшә-сөйләшә, китеп бардылар.
86. Мин аңа ияреп йөрим.
87. Рөстәм тырыша-тырыша яза башлады.
88. Туган нигездә, карт тополь төбендә, укып утырам. (М.Мәһдиев)
89. Аскы рәттәге калын-калын ботакларын кинәт кенә җиргә таба борып, үз төпләрен үзләре төреп алганнар, агач төбенә бернинди кар, буран үтә торган түгел. (М.Мәһдиев)
90. Монда яңа сугылып, кичә тарттырылган бодай оныннан пешергән кабартма исе – бары тик шул ис кенә килә! (М.Мәһдиев)
91. Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы агачларга посып. (Г.Тукай)
92. Миңа озын гомер тели-тели,
Кем булды, дип, улым-алтыным,
Өйдән өйгә йөреп укыр идең
Окопларда язган хатымны... (Ф.Кәрим)
93. Айсылу аңа елмаеп карады. (З.Кәримов)
94. Укучыларның тырышып эшләгәнен Вәли абый шатлык белән күзәтеп торды.(Х.Зарипов)
95. Алмаз сатып алган әйберләрен көч-хәл белән күтәреп кайтты. (Х.Зарипов)

**6. Исем фигыль**

**Биремнәр:**

1. Исем фигыльләргә тулы морфологик анализ ясарга.

Үрнәк: ишетүгә - исем фигыль, затланышсыз, барлыкта, төп юнәлештә, юнәлеш килешендә, берлек санда, тартымсыз, җөмләдә аерымланган вакыт хәле составында, тамыр сүз.

2. Исем фигыльләрнең исемгә күчү очракларына мисаллар китерегез.

1. Бер-ике минут үтү белән, арадагы пәрдә югалды.

(Г.Ибраһимов)

2. Ләкин бу ел көзгә таба мин аңарда бераз йомшару әсәре күрә башладым. Шул йомшаруның башлануына бер ай дигәндә, картның чыбыркы тотып, сыер артыннан йөрерлек чамасы бөтенләй бетте. (Г.Ибраһимов)

3. Армиядән кайтуына яңа тракторга утырттылар. (Ф.Яруллин)

4. Сагыну борчуы аның түсенә чыкты, ахырысы, ул, ябыгып, тагын да озынаеп китте. (А.Гыйләҗев)

5. Кол булмыйча, азат илдә хөр булып яшәү, иҗат итү, яңаны тудыру... шуннан да кыйммәтлерәк нәрсә бар? (Г.Әпсәләмов)

6. Хәлимнең башына бәргәндәй булды бу үртәү. Ничек итеп яр буена барып җитүе дә, ай яктысында резин калфакны кармалап табуы, сулышы кабып кире лагерьга йөгереп кайтуы да төштәге сыман тоелды Хәлимгә. (Л.Сабирова)

7. Кичәдән бирле ике тау арасында карлыган утырту бара. (И.Гази)

8. Иң беренче эшем – мәктәп ишекләрен киң итеп ачып җибәрү һәм беренче звонок бирү, - диде Сентябрь. (Г.Галиев)

9. Кешенекен алу – үзеңнекен югалту. (Мәкаль)

10. Әтисе белән күрешүен күз алдына китергәч, Тәнзилә янә каушап калды. (Н.Акмалов)

11. Урман үзенең саф һавасын, матурлыгын, барлык нигъмәтләрен бүләк итә безгә. (Г.Мөхәммәтшин)

12. Атналар үтү белән, гомумән, шәһәрдә шау-шу сирәгәю белән, Хәлим тынычланып китте. (Г.Гобәй)

13. Әхмәтнең күңелен күтәрерлек бүтән сүз таба алмау сәбәпле, мин аны Җыен бәйрәменә кунакка чакырдым. (Г.Бәширов)

14. Хөсәен, кызыксынудан һәм аптыраудан сулышын кысып, урыныннан кузгала алмыйча, һаман тәрәзәдән карап торды. (А.Расих)

15. Өлкәннәр көнен үткәрүгә әзерлек көннәрендә, без, хезмәт ветераннары белән очрашу кичәсендә булдык. (К.Тимбикова)

16. Бер карауда сине табармын мин,
Бер карауда сине танырмын... (Х.Туфан)

17. Солдат белән бергә ил саклауда хезмәт итә икән китабы.

(Г.Афзал)
18. Бару белән үрдәк күлгә төшеп китте. (М.Гафури)
19. Вакытының үтүе дә тоелмый. Дулкын кузгалды, калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр. Балык чиртүе дә беленми башлады. (А.Алиш)
20. Мин үскән урын
Нинди киң әнә,
Һәр җиргә ямьне
Бирәм мин генә.
Бу масаюны
Бакчада булган
Роза чәчәге
Ишетеп алган. (З.Мансур)
21. Күрче, бик чынлап керешкән эшкә безнең Ламига,
Бар уе бер бик матур күлмәк тегү курчагына. (Г.Тукай)
22. Табибның иң изге бурычы – киң җәмәгатьчелек арасында медицина, санитария белемнәре тарату. (Г.Әпсәләмов)
23. Вагоннар тирәсендә бүген халык җыелган, әллә нәрсәләр турында кызу-кызу сөйләшү бара. (Ш.Усманов)
24. – Ах, җүләр маэмай!
Тырыш яшьләй.
Зурайгач, җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар –
Эш белү уңайсыз ул! (Г.Тукай)
25. Балык тоту, баллы көпшә, балтырган, какы, кузгалак, җиләк, колмак, чия, чикләвек, балан җыюлар да яртылаш уеннан тора иде. (М.Юныс)
26. Ипи салу – хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше. (М.Мәһдиев)
27. Тавык белән каздан башканы күрмәгән күзгә, мондый күк гөмбәзе кунагын күрү, бик көтелмәгән хәл булып чыкты, минем күзләр яшьләнде, тамак төбе кипте. (М.Мәһдиев)
28. Дәрес бетүгә, ашханәдә бутерброд капкалап кына эшкә тотынган идек, сөйләшә-сөйләшә, ватман өстендә мәш килгәндә, вакытның узуы сизелмәгән дә.

29. Теге көнне бергә киногa баруларын шул хәтле оста яшерәләр!
30. Мәктәптә күренмәве дә тикмәгә генә түгелдер әле ... (А.Гыймадиев)
31. Төн уртасы җитү белән, шәһәр читенә чыга да теге өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә. (Әкият)
32. Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп. (Мәкаль)
33. Телләр белү – илләр белү. (Мәкаль)
34. Бер як, кулларын бутый-бутый, көрәштерүне, икенче як көрәштермәүне куәтләде. (Ә.Фәйзи)
35. Шушы күлләрдә, Ыкта көймәдә йөрүләре, балык каптырулары, су коенулары искиткеч күңелле. (Г.Мөхәммәтшин)
36. Гафиятулла бабайның өе кечкенә булганлыктан, Газинур, озакламыйча, әти-әнисенең ризалыгын алып, башка чыкты. (Г.Әпсәләмов)
37. Маяклар сүнүгә, пароходның тирә-ягы бөтенләй караңгыланып китте. (Г.Гобәй)
38. Кыз кемнең бакчасына таш атылганны аңлады. (Г.Ибраһимов)
39. Ит күтәреп, өстәл күтәреп, кунаклар арасында тыз да быз чабып йөрүләр тиздән тынып калды. (Н.Фәттах)
40. Мөстәкыйльлек идеясен тәмам юкка чыгару өчен, Казан ханлыгы дигән исем дә тыела. (Г.Исхакый)
41. Уңганлыкка олы сынау
Яшь киленнең һәр эше. (Җыр)
42. Кешегә үзенең гамәле турында хөкем чыгару бик читен. Ул гомер юлын бер генә тапкыр уза. Әлбәттә, кылган эшләре турында кеше уйланырга мәҗбүр була. (Ә.Еники)
43. Һәммә кешенең кызыгып сөйләгән шул сабак уку, мине бераз һаваландырды. (Г.Исхакый)
44. Ул бәйрәм көннәрендә картның намаздан кайтуына коймак әзерләп куя иде. (Г.Исхакый)
45. Өй җыештыру да, бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. (Г.Исхакый)

46. Алай гына да түгел, экспедиция әгъзалары, шул рәттән Борһан Шәрәф тә Үзбәкстан Корылтаеның бер мәҗлесендә катнашу бәхетенә дә ирештеләр. (Мирас журналы)
47. Күрәсең Борһан Шәрәф өчен чит илгә качып китү бер төрле “жуликлык”, яисә кемгәдер хезмәт итү йөзеннән генә эшләнә торган эш кебек күренгәндер. (Мирас журналы)
48. Бик озак йоклый алмаенча уйлап торганның соңында, ул өйләнү фикеренә килде. (Г.Исхакый)
49. Бару белән үрдәк күлгә төшеп китте.
50. Вакытның үтүе дә тоелмый.
51. Хәзер елга аша чыгу юк.
52. Китап уку бик рәхәт тә, күңелле дә ул.
53. Кол булмыйча, азат илдә хөр булып яшәү, иҗат итү, яңаны тудыру...шуннан да кыйммәтлерәк нәрсә бар! (Габдерахман Әпсәләмов)
54. Мин күрүгә, Алмачуар кешнәп җибәрде. (Галимҗан Ибраһимов)
55. Син миңа ничек яралануыңны сөйләмәдең бит әле! (Гомәр Бәширов)
56. Кайтып керүгә атасыннан исәнлек-саулыклар һәм абыйларын сорашып, хәбәр-хәтердән соң патша моңарга:
- Менә иң өлкән абыеңның китүенә ике ел, уртанчыларына бер ел булды, һичбер хәбәр-хәтерләре юк,- диде. (Тылсымлы әкият “Ак бүре”)
57. Энесе, агасына үзенең кем булганын сөйләп:
- И агай, мин синең иң кечкенә энең булам.
58. Шул заманда, бик каты ышкуга чыдый алмыйча, алтмыш колачлы алтын тирәк шартлап төбеннән сынды.
59. Ә кем тынычлыкны бозучы?
60. Мин олырак кеше, минем бурычым – сезне кисәтү.
61. Без сөйләшүне кичен дә дәвам иттек.
62. Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлау белән, тизрәк, Казанга китәргә ашкынуымда да, һичшиксез, олы әдипнең тәэсире бар иде.
63. Бер урыннан икенче урынга күчү кинәт тукталды.

64. Анда бар моң, йөрәктән тулып ташыган сагыну моңы, сагыш дулкынланды.
65. Су тавышы – моң агышы:
Әллә кавышу, әллә аерылышу? (Р.Гаташ)
66. Беренче тәэсиргә карап кына кеше турында фикер йөртү кыен. (М.Хәсәнов)
67. Синең килүең кирәк түгел.
68. Иртән зарядка ясау сәламәтлек өчен файдалы.
69. Вакытның үтүе дә тоелмый.
70. Син яшәүнең кызыгын белмисең.
71. Атна – ун көн үтүгә, Заһри китте.
72. Кайтып җитү берлән, самовар берлән көтеп тора торган остазбикәгә хәлне сөйләгәч, ул да курыкты. (Г.Исхакый)
73. Өйләнешү бит ул – ике кешенең язмышын бергә төенләп бәйләү дигән сүз. (Ә.Еники)
74. Шуннан соң һәр көнне кич берлән агачка су китереп сибүне гадәт итте. (Г.Исхакый)
75. Казылган шул килеш күмелмичә ятты. (Р.Камалов)
76. Инженерга уку беркайчан да җиңел булмады. (А.Аюпов)

**7. Инфинитив**

**Биремнәр:**

1. Инфинитив фигыльләрдә юнәлеш формаларын күрсәтергә.
2. Инфинитивның төрле җөмлә кисәкләре була алуын күрсәтергә.

1. Мәскәү ерак. Тик бер генә тапкыр Ленинны соң ничек күрергә? (С.Хәким)
2. Нигә шулкадәр кыйналырга, кичерергә! (А.Расих)

3. Кайтып күрергә иде туган якларны! (Г.Тукай)
4. Әйе, мин аны сөйдем. Сөйгәнемнең кәефен бозмас өчен, мин лекциядә бер генә мөһим сүзне дә төшереп калдырмаска, төннәр буе өстәлдә утырып, бер генә сүзне дә ялгыш язмаска тырыштым. (Г.Кутуй)
5. Сылу янында утырырга хаклы булу өчен, мин еш кырынырга,

чиста йөрергә өйрәндем. (Г.Кутуй)
6. Бүген безгә үзебезнең сүзне ачык итеп әйтергә кирәк. (Г.Толымбай)

7. Үләнгә - борынлап чыгарга, яшәргә... Тагын җиргә сеңәргә.
Ташка – җилдән ярылырга, яңгырдан уелырга... Җиргә иңәргә.
Кошка – талпынырга, җил кочагына атылырга, аннан... Җиргә.
Миңа – нәфрәттән мәхәббәткә кадәр
күтәрелергә,
күтәрелергә,
күтәрелергә... (Р.Фәйзуллин)

8. Хуш, мәктәп, үз күрдең, яшәргә көч бирдең... (С.Сөләйманова)
9. Кешенең үзе генә ниятләгән эшләре дә булырга мөмкин бит. (К.Тимбикова)

10. Миңа әле иртә бугай
Күз турында уйларга.
Күз турында уйламаска,
Уйларга яз турында.
Миңа язгы сулар кебек
Уйнарга да уйнарга.
Нәтиҗәгә ашыкмаска,
Дәвамга омтылырга. (Г.Рәхим)

11. Язучылар да кайда да булса хезмәт итәргә, өй карарга, балалар үстерергә, шуннан калган вакытын, йокысыз төннәрен иҗатына бирергә мәҗбүр икән ләбаса. (Л.Ихсанова)
12. Мин Әминә Бикчәнтаеваның “Такташлар, Җәлилләр, Туфаннар...” турында сөйләгәнен тыңларга ярата идем. (Л.Ихсанова)
13. Солдат-мазар очрап сорашырга тотынса, урманга гөмбәгә

барам диярсең. (Г.Гобай)
14. Хат-хәбәр юк, үлде, ахры, диеп,
Ашыкмагыз дога кылырга.
Авыр үлем белән көрәшәбез,
Исәп әле тере калырга.
Теләгебез, сыерчыклар кебек,
Тагын илгә очып кайтырга.
Сезнең белән елап күрешеп,
Тагын бергә рәхәт татырга. (А.Алиш)
15. Тынычлар өчен, өй эшләре белән дә онытылып булыша башлады. (А.Расих)
16. – Иптәшләр, җыелышны ачык дип белдерергә рөхсәт итегез.
17. Беренче тапкыр кулга каләм алып, сиңа хат язарга утырдым.
18. Мин бу хәлне беркемгә дә сөйләмәскә, сиздермәскә булдым. (И.М.Низамов)
19. Ул сул як күршесе белән бераз гәпләшеп утырырга ниятләде. (Әдәбият китабы)
20. Диюне җиңәр өчен миңа көч җыярга кирәк. (Әкият)
21. Мин сиңа сабакларымны тыңлатмакчы булдым. (Ф.Әмирхан)
22. Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып. (Х.Туфан)
23. Сакларга кирәк, юк, тагын да ныгытырга кирәк табигать белән дуслыкны. (Г.Бәширов)
24.Землянкалардан өч йөз метрда дошманның посты тора, менә шуңа һөҗүм итәргә кирәк. (Г.Әпсәләмов)
25. Син кая барсаң, миңа да шунда булырга рөхсәт бир. (Ш.Усманов)
26. Безнең авыл янында ясалма диңгез барлыкка килгәннән бирле, без, балыкка йөрергә өйрәнеп, күнегеп киттек. (Ф.Хөсни)
27. Димәк, сез яралыны озатырга кеше таба алмыйсыз, алайса санитарный поездны көтәргә кала. (Ш.Усманов)
28. Салкын тиз генә сынарга исәпләми. (Ә.Гаффаров)
29. Аны күрүгә оядагы куяннар да үрле-кырлы сикерешергә тотындылар. (Л.Сабирова)
30. Озатырга чыкты туган авыл,

Тагын китәм язмыш эзеннән. (Җыр)
31. Кичә генә ул әллә ниләр эшләмәкче, тау-ташларны актармакчы иде. (Календардан алынган)
32. Шүрәле фөрьят итәдер, аудан ычкынмак була;
Һәм дә, ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була. (Г.Тукай)
33. Эшне башларга ашыкма, тәмамларга ашык. (Мәкаль)
34. Абынырга түмгәк табыла. (Мәкаль)
35. Ялкау ял итәргә дә авырсыныр. (Мәкаль)
36. Мәктәптә әле һаман окоп казырга килгән солдатлар яши. (Ш.Галиев)
37. Аның белән барырга булдым. (Ш.Галиев)
38. Ул ярата җырларга,
Мин яратам тыңларга. (Табышмак)
39. Мин инде җырчы булырга, артист булырга хыялланам. (М.Мәһдиев)
40. – Син, Гайфи абый, шаярып сөйләшергә өйрәнгәнсең икән... (М.Мәһдиев)
41. Уйнарга, көләргә яраткан, тормышның яхшы якларын гына күрергә өйрәнгән Сылуның юлдашы, моңарчы гел шатлыктан гына тора иде.
42. Балыкка барганда ачык төстәге кием кияргә кирәк.
43. Әминә әкият тыңларга ярата.
44. Марат тиз барырга тырышты.
45. Безгә тырышып эшләргә кирәк.
46. Костин взводка таба борылды:
Атлардан төшәргә! (Гариф Гөбәй)
47. Бер көн киңәш иткәннәр дә үги кызны урманга илтеп адаштырмакчы булганнар. (Әкият)
48. Кендек артыннан уртага кергән утыз сум Гыймади белән Вәли Хәсәновны кара-каршы сүз алышырга мәҗбүр итте. (Г.Ибраһимов)
49. Беренче тапкыр Академия театрында булырга туры килде...(М.Мәһдиев)
50. Нәфис мине озатырга чыкты. (С.Рәмиев)
51. Ләкин шул кадәресе дә яшь күңелне очындырырга җитә

калды...
52. Кояш шул болыт кисәге астында калганга, көн бераз тыныграк.
53. Пристаньга беренче төшүе булганга, аңа бөтенесе яңа.
54. Аз гына, бик аз гына түзәргә, сабыр итәргә кирәк.
55. Борылырга да, утырырга да бирмиләр.
56. Галимҗан ага үзе дә нишләргә дә белми.
57. Сакларга кирәк, юк, тагын да ныгытырга кирәк табигать белән дуслыкны. (Г.Бәширов)
58. Мин аңа сабакларымны тыңлатмакчы булдым. (Ф.Әмирхан)
59. Дәрестә тәрәзәгә карап утырырга ярамый, укытучыны тыңларга кирәк.
60. Син әниеңә нинди бүләк әзерләргә уйлыйсың?
61. Яңа тема авыр, ләкин без аңларга тырышабыз.
62. Ул бит сиңа ашарга пешерә.
63. Калырга, тырышып укырга кирәк.
64. Әйдә, балам, сиңа йокларга вакыт. (Р.Миңнуллин)
65. Җыр хакына,
Гомер багышларга,
Кайсыгыз соң әзер, туганнар? (Х.Туфан)
66. Әмма боларның берсе дә көннәрдән бер көнне миңа гашыйк булырга комачау итмәде. (М.Мәһдиев)
67. Укырга, укырга һәм тагын укырга! (Ленин)
68. Алмаз авылга кайтырга теләк белдерде. (В.Авзалов)
69. Сара озак йокларга ярата. (В.Авзалов)

**Учебное издание**

**Мирдиянова Б.М.**
**Заripова Г.Г.**

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## МОРФОЛОГИЯ

МЕТОДИЧЕСКИЕ УКАЗАНИЯ

Корректор Габдурахимова Т.М.
Худ. редактор Федорова Л.Г.

Сдано в набор 02.02.2012.
Подписано в печать 13.02.2012.
Бумага писчая. Гарнитура Таймс.
Усл. печ. л. 2,7. Тираж 100.
Заказ №8.

НХТИ (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ»,
г. Нижнекамск, 423570, ул. 30 лет Победы, д. 5а.